**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2023 елның 05 мае** **57-РС номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2020елның 05 июнендәге 32-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2017 елның 14 августындагы 43-РС номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2020елның 05 июнендәге 32-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның 2 абзацында "Татарстан Республикасы Президентын" сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгын (Рәисе)» (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисен) сүзләре белән алыштырырга";

4 пунктта "Татарстан Республикасы Президентын" сүзләрен»Татарстан

Республикасы Рәисен " сүзләре белән алыштырырга;

5 пунктның 2 абзацында "Татарстан Республикасы Президентын" сүзләрен»Татарстан Республикасы Рәисен " сүзләре белән алыштырырга;

6 нчы пунктның 1 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Рәисенең белдерүе Лаеш муниципаль районы Советының 2020 елның 06 июлендәге 36-РС номерлы карары белән расланган Совет Регламентында (алга таба - Регламент) билгеләнгән тәртиптә Совет утырышында карала.»;

в 7 пунктның 1 һәм 3 абзацларында «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башлыгы урынбасары - Совет рәисе урынбасары Т.П. Борһановага йөкләргә.

**Башлык –муниципаль**
**район Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**